КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 гыйнвар г.Казань № 29

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булучы (булган) Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булучы (булган) Россия Федерациясе гражданнарын, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны

урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 20 май, 479 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 25 август, 896 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «территорияләрендә» сүзе алдына «, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе» сүзләрен өстәргә, «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән» сүзләренә алмаштырырга;

преамбулада «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта татар текстында «территорияләрендә» сүзе алдына «, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе» сүзләрен өстәргә, «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булучы (булган) Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибендә:

исемендә татар текстында «территорияләрендә» сүзе алдына «, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе» сүзләрен өстәргә, «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта татар текстында «территорияләрендә» сүзе алдына «, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе» сүзләрен өстәргә, «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән» сүзләренә алмаштырырга, «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнар» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнар» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнар» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнарны» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыру һәм туклану чыгымнарын каплау турында» 2022 ел, 30 апрель, 406 нчы карары белән билгеләнгән форма буенча торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган затлар исемлеген;»;

11 пунктның унөченче абзацында «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнарны» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарны» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

дүртенче абзацта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнар» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән, Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнарның» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән, Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнарның» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктта «Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнар» сүзләрен «торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән һәм Татарстан Республикасы территориясенә килгән гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

бу Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 30 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны ташлап китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктларында булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм туклануга бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе территорияләрендә даими яшәгән, торак урыннарны мәҗбүри ташлап киткән Россия Федерациясе гражданнарыны, чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны вакытлыча урнаштыру һәм туклану пунктлары урнашкан оешмалар исемлеге

| Т/с | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан муниципаль берәмлек исеме | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешма исеме | Вакытлыча урнаштыру һәм туклану пункты урнашкан оешманың почта адресы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Яр Чаллы шәһәре | «КАМАЗжилбыт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Яр Чаллы шәһ., Академик Рубаненко ур., 6 нчы й. |
| 2. | Яр Чаллы шәһәре | «Жемчужина» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Яр Чаллы шәһ., Мәләкәс ур., 1 нче й. |
| 3. | Казан шәһ. | «КВАРТ» Кама-Идел резино-техника акционерлык җәмгыяте» акционерлык җәмгыяте («КВАРТ» акционерлык җәм- | Казан шәһ., Техник ур., 25 нче й. |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | гыятенеӊ кунакханә-торак комплексы) | |
| 4. | Казан шәһ. | «Ливадия-Татарстан» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Казан шәһ., Себер тракты ур., 192 нче а/т |
| 5. | Казан шәһ. | Индивидуаль эшмәкәр Әбүшахманова Гөлнара Рафаил кызы («Второй Дом» кунакханәсе) | Казан шәһ., Калинин ур., 60 нчы й., 53 нче ф. |
| 6. | Казан шәһ. | «Экспресс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте («Экспресс» хостеле) | Казан шәһ., Сәетгалиев ур., 6 нчы й. |
| 7. | Казан шәһ. | Индивидуаль эшмәкәр Гарбуз Михаил Иосифович («Отель Стрела») | Казан шәһ., Рәвис Гәрәев ур., 78 нче й. |
| 8. | Алабуга муниципаль районы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (Алабуга институты (филиал)) | Казан шәһ., Кремль ур., 18 нче й. |
| 9. | Зеленодольск муниципаль районы | «Васильевский» шифаханәләр һөнәр берлекләре дәвалау-профилактика хосусый учреждениесе | Зеленодольск муниципаль районы, Васильево пос., Шифаханә территориясе урамы,1 нче А йорт |
| 10. | Лаеш муниципаль районы | «Санта» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Казан шәһ., Пушкин ур., 12 нче й. |
| 11. | Лаеш муниципаль районы | «Санта Регина» шифаханәсе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | Казан шәһ., Җиңү пр., 105 нче й., 4 нче оф. |